Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«20» ноябрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатыннан су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Үрнәк авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, кулланылган асфальт җәю (сатып алу, ташу, җәю), чокырларны ремонтлау (юеш коелган асфальт);

- Үрнәк авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

- авыл җирлеге торак пунктлары, урамнарны, территорияләрне, Үрнәк авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу);

- Үрнәк авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И. Кашапова